# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлегенең Абалач
торак пунктында 2024 елда
гражданнарның үзара салымын кертү турында

**7 апрель 2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2024 елның 28 мартындагы 2 номерлы “2023 елның 21 ноябрендәге 4 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Абалач авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 21 ноябрендәге 3 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Абалач авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында карары нигезендә

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

2023 елның 21 ноябрендәге 4 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Абалач авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 21 ноябрендәге 3 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Абалач авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертергә һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Абалач авылында автомобиль юлларын карап тоту өчен МТЗ-82 тракторы өчен фронталь йөк төягеч сатып алу);

2) Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Абалач авылына 2 (ике) данә су насосы сатып алу);

3) Торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру ,балалар мәйданчыгы өчен койма ясау һәм урнаштыру, җәйге вакытта үлән чабу, Абалач авылында кече архитектура формасын урнаштыру;

4) һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Абалач авылында һәйкәл территориясендә Үлемсез полк стендын әзерләү һәм урнаштыру);

5) каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү. (Абалач авылында 4 данә чүп контейнерлары сатып алу);"

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Абалач авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Абалач авыл җирлеге башлыгы Л.А. Шияпова